СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Бурнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.07.2019 с. Татарское Бурнашево 63-289

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

**2019 елның 2 кварталында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап**

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Башлыгы Бурукин Сергей Валерьевич мәгълүматын тыңлаганнан һәм карап тикшергәннән соң,

**Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге бюджетының 2019 елның 2 кварталы өчен үтәлеше турында хисапны кабул итәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

**Совет Рәисе,**
**ТР Югары Ослан муниципаль районы**
**Бурнаш авыл җирлеге Башлыгы С.В. Бурукин**

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советының
№ 63-289 24.07.2019 г ел карарына
Кушымта

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге бюджетының 2019 елның 2 кварталына үтәлеше турында хисап**

Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлегенең төп финанс документы булып Советның 2019 елның 19 декабрендәге №57-257 карары белән кабул ителгән Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге бюджеты тора.

Авыл җирлеге бюджеты, үзгәрешләр һәм өстәмәләрне исәпкә алып, 2 998,7 мең сум күләмендә расланды һәм 905,8 мең сум (30,2%) үтәлде.

Авыл җирлеге бюджетының керем өлеше түбәндәге салымнар хисабына формалашкан:

1. Физик затлар кеременә салым - 48,2 мең сум
2. Милеккә салым - 20,5 мең сум
3. Җир салымы - 573,1 мең сум.
4. Түләүле хезмәтләр һәм чыгымнарны кайтару – 73,6 мең сум
5. Үзара салым акчалары - 188,7 мең сум
6. Штрафлар - 1 мең сум

Статьялар буенча салым һәм салым булмаган керемнәрнең җентекле үтәлешен тикшерәбез:

- физик затлар керемнә салым 52.4 **%** үтәлгән (план 92 мең сум булганда 48,2 мең сум акча җыелган);
- мөлкәткә салым 6,7 **%** (план 308 мең сум булганда, 20,5 мең сум,);
- җир салымы 23,8 **%** (план-2 409,5 мең сум булганда, 573,1 мең сум,).

2019 елның 1 июленә авыл җирлеге бюджеты чыгымнар буенча 1 525,1 мең сум, (план буенча 2 901,3 мең сум булганда) яки еллык план билгеләнешеннән 52,6% үтәлгән, шул исәптән бүлекләр буенча:

- 2019 елга план буенча Авыл җирлеге белән идарә итүгә чыгымнар. – **1 296,4 мең сум**, факт **-677,2 мең сум** (52,2 **%)** тәшкил итә**;**
- мәдәнияткә чыгымнар 2019 елга план буенча – 407,0 мең сум, факт **91,3 мең сум** (22,4 **%** үтәлеш) тәшкил итә;
- ДПО янгын чыгымнары, янгынга каршы чаралар планда – **332,5** мең сум, факт 122,9 мең сум (37**%)** тәшкил итә;

**Примечание [P1]:**

- 2019 елга план буенча төзекләндерүгә чыгымнар (үзара салым акчаларын исәпкә алмыйча) – 696,6 мең сум, факт 508,1 мең сум **(72,9 %** үтәлеш) тәшкил итә.

***<u>Шул исәптән:</u>***

– урам яктыртылышына еллык план буенча **284,6** мең сум, факт **218,6** мең сум тәшкил итә, үтәлеш 76,8 **%**. Урамнарны яктыртуга чыгым калдыгы – **66,1** мең сум**;**

- юлларны карап тоту еллык план буенча **207,2** мең сум, факт **198,0** мең сум (95,6 **%)** тәшкил итә**;**

- коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларга чыгымнар, шул исәптән, 2019 елга план буенча су суырту 82,4 мең сум, факт 82,4 мең сум (**100%)** тәшкил итә;

- бюджетка тискәре трансфертлар – план 83,5 мең сум, факт 83,5 мең сум (100%) тәшкил итә;

- районга бюджетара трансфертлар - план 504, мең сум, факт 378,38 мең сум (75,0 %) тәшкил итә.